«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 9 сентябрендәге 679 номерлы Татарстан Республикасы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балалы гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру буенча нәтиҗәле эшне оештыру максатыннан Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә кертергә, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы карары белән (2013 елның 04 октябрендәге 686 номерлы редакциядә) «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Компенсацияләр алуга хокукны билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган кереме «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр керткәндә гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.»;

2.1 пунктында:

1) Ƅ пунктчада «өч ай эчендә» сүзләрен «соңгы алты календарь айда» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Вәкаләтле органга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, эш бирүче (страхователь) физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр суммасы турында белешмә алу мөмкинлеген бирүче мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң, компенсация билгеләү аның ризалыгында күрсәтелгән гаризада күрсәтелгән Россия Федерациясе Пенсия фондында булган белешмәләр нигезендә, соңгы 6 айда, гариза бирүчегә компенсация сорап мөрәҗәгать иткән 12 айдан алда.».

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е. А. Тарнавскийга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов